ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

25.05. 2020 ел. № 105

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегендә бюджет процессы турында «Нигезләмәне раслау хакында» гы 11.12.2011 ел, №11 карарына (Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Советының 26.05.2014 ел, № 27; 15.10.2015 ел, № 9 карарлары редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 ел, 27 декабрь, 199-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының парламент контролен камилләштерү өлешендә 264.4 статьясына үзгәреш кертү турында» 2019 ел, 26 июль, 203-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының "Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә бюджет процессы турында" Нигезләмәне раслау хакындагы (Аксубай муниципаль районының Советы __ нче номерлы карарлары редакциясендә)" 2011 ел, 8 декабрь, 7 нче номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Бюджет акчаларының баш администраторлары бюджет хисаплылыгын төзи һәм аны финанс органына билгеләнгән срокларда тапшыралар.

1.2. Нигезләмәнең 14 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, РФ Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, җирлек Советының муниципаль норматив-хокукый актында билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. 16 статьяның 2 пунктын өстәргә:

Бюджет үтәлешен һәм бюджет хисабын анализын үз эченә алган бюджетүтәлеше турында еллык хисапка аңлатма язма.

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеттан башлап, җирлек бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http: //Aksubaevo. tatarstan. ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http: //pravo. tatarstan. ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге Советы рәисе: В.З.Николаев